**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «Об образовании»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
19 декабря 2018 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 22 июля 2013 года № 68-ЗРТ «Об образовании» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2013, № 7; 2014, № 7; 2015, № 3, № 10 (I часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2016, № 3 (часть I), № 40 (часть I); 2018, № 1 (часть I), № 54 (часть I) следующие изменения:

1) часть 2 статьи 3 дополнить пунктами $15^1$ и $15^2$ следующего содержания:

«$15^1$) установление квоты приема на целевое обучение по образовательным программам высшего образования за счет бюджетных ассигнований бюджета Республики Татарстан, утверждение порядка и сроков ее установления;

$15^2$) установление порядка выплаты штрафа за неисполнение обязательств по договору о целевом обучении по образовательным программам высшего образования, предусмотренного частью 6 статьи $71^1$ Федерального закона, порядка и оснований освобождения сторон договора о целевом обучении от его выплаты, порядка определения его размера и направления на финансовое обеспечение образовательной деятельности по образовательным программам высшего образования, осуществляемой за счет средств бюджета Республики Татарстан;»;

2) в части 4 статьи 19 слова «вправе осуществлять в пределах установленных им контрольных цифр приема целевой прием в порядке, утвержденном в соответствии со статьей 20 настоящего Закона» заменить словами «осуществляют прием на целевое обучение в пределах установленных контрольных цифр приема в порядке, установленном статьей $71^1$ Федерального закона»;

3) статью 20 изложить в следующей редакции:

«Статья 20. **Целевое обучение**

1. Гражданин, поступающий на обучение по образовательной программе среднего профессионального или высшего образования либо обучающийся по соответствующей образовательной программе, вправе заключить договор о целевом обучении с федеральным государственным органом, органом государственной власти Республики Татарстан, органом местного самоуправления, юридическим лицом или индивидуальным предпринимателем (далее – заказчик целевого обучения). Существенные условия договора о целевом обучении устанавливаются в соответствии с Федеральным законом.

2. Сторонами договора о целевом обучении наряду с гражданином, указанным в части 1 настоящей статьи, и заказчиком целевого обучения могут также являться организация, осуществляющая образовательную деятельность, и (или) организация, в которую будет трудоустроен гражданин в соответствии с договором о целевом обучении.

3. Организация, осуществляющая образовательную деятельность, в которой обучается гражданин, заключивший договор о целевом обучении, учитывает предложения заказчика целевого обучения при организации прохождения указанным гражданином практики, а также по запросу заказчика целевого обучения предоставляет ему сведения о результатах освоения им образовательной программы.

4. В случае неисполнения заказчиком целевого обучения предусмотренных договором о целевом обучении обязательств по трудоустройству гражданина, заключившего договор о целевом обучении, заказчик целевого обучения выплачивает ему компенсацию в размере трехкратной среднемесячной начисленной заработной платы в соответствующем субъекте Российской Федерации, на территории которого он должен был быть трудоустроен в соответствии с договором о целевом обучении, на дату отчисления его из организации, осуществляющей образовательную деятельность, в связи с получением образования (завершением обучения).

5. В случае неисполнения гражданином, заключившим договор о целевом обучении, предусмотренных договором о целевом обучении обязательств по освоению образовательной программы и (или) осуществлению трудовой деятельности в течение трех лет он обязан возместить заказчику целевого обучения расходы, связанные с предоставлением мер поддержки.

6. Кабинет Министров Республики Татарстан определяет и размещает на официальном сайте в сети «Интернет» перечень приоритетных направлений подготовки (специальностей), реализуемых образовательными организациями по имеющим государственную аккредитацию образовательным программам среднего профессионального и высшего образования, в целях удовлетворения потребности государственных и муниципальных организаций в специалистах соответствующей квалификации.

7. Положение о целевом обучении, включающее в том числе порядок заключения и расторжения договора о целевом обучении, условия определения и изменения места осуществления трудовой деятельности, порядок и основания освобождения сторон от исполнения обязательств по договору о целевом обучении, порядок выплаты компенсации, порядок определения размера расходов и их

возмещения, и типовая форма договора о целевом обучении устанавливаются Правительством Российской Федерации в соответствии с Федеральным законом.

8. Гражданин, заключивший договор о целевом обучении с органом государственной власти Республики Татарстан, органом местного самоуправления в Республике Татарстан, государственным (муниципальным) учреждением, унитарным предприятием, государственной компанией или хозяйственным обществом, в уставном капитале которого присутствует доля Республики Татарстан или муниципального образования в Республике Татарстан, имеет право на меры государственной поддержки граждан в системе социальной ипотеки в соответствии с Законом Республики Татарстан от 27 декабря 2004 года № 69-ЗРТ «О государственной поддержке развития жилищного строительства в Республике Татарстан».

9. Особенности заключения договора о целевом обучении, стороной которого является государственный орган или орган местного самоуправления и который включает в себя обязательство гражданина, заключившего договор о целевом обучении, по прохождению государственной службы или муниципальной службы после завершения обучения, определяются в порядке, установленном федеральными законами о видах государственной службы или законодательством о муниципальной службе.

10. Кабинет Министров Республики Татарстан обеспечивает ведение органами исполнительной власти Республики Татарстан мониторинга трудоустройства граждан, получивших профессиональное образование по договору о целевом обучении за счет бюджетных ассигнований бюджета Республики Татарстан и местных бюджетов муниципальных образований в Республике Татарстан, по итогам очередного учебного года и размещение его на официальных сайтах органов исполнительной власти Республики Татарстан в сети «Интернет» не позднее 1 сентября.»;

4) часть 4 статьи 25 изложить в следующей редакции:

«4. Педагогическим работникам образовательных организаций, участвующим по решению органа исполнительной власти Республики Татарстан, осуществляющего государственное управление в сфере образования, в проведении государственной итоговой аттестации по образовательным программам основного общего и среднего общего образования в рабочее время и освобожденным от основной работы на период проведения указанной государственной итоговой аттестации, предоставляются гарантии и компенсации, установленные трудовым законодательством и иными актами, содержащими нормы трудового права. Педагогическим работникам, участвующим в проведении государственной итоговой аттестации по образовательным программам основного общего и среднего общего образования, выплачивается компенсация за работу по подготовке и проведению указанной государственной итоговой аттестации. Размер и порядок выплаты такой компенсации устанавливаются Кабинетом Министров Республики Татарстан в пределах средств бюджета Республики Татарстан, выделяемых на проведение государственной итоговой аттестации по образовательным программам основного общего и среднего общего образования.».

**Статья 2**

1. Настоящий Закон вступает в силу с 1 января 2019 года.

2. Действие положений Закона Республики Татарстан от 22 июля 2013 года № 68-ЗРТ «Об образовании» (в редакции настоящего Закона) не распространяется на правоотношения, возникшие из договоров о целевом приеме и договоров о целевом обучении, заключенных до дня вступления в силу настоящего Закона.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ *
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
20 декабря 2018 года
№ 105-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Мәгариф турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 19 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Мәгариф турында” 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; 2014, № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 3 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле $15^1$ һәм $15^2$ пунктлар өстәргә:

“$15^1$) Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән югары белем бирүнең уку-укыту программалары буенча максатчан укытуга кабул итү квотасын билгеләү, аны билгеләүнең тәртибен һәм срокларын раслау;

$15^2$) югары белем бирүнең уку-укыту программалары буенча максатчан укыту турында шартнамә йөкләмәләрен үтәмәгән өчен Федераль законның $71^1$ статьясындагы 6 өлешендә каралган штрафны түләү тәртибен, максатчан укыту турында шартнамә якларын аны түләүдән азат итү тәртибен һәм нигезләрен, аның күләмен билгеләү һәм аны югары белем бирүнең уку-укыту программалары буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган белем бирү эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүгә җибәрү тәртибен билгеләү;”;

2) 19 статьяның 4 өлешендә “үзләренә билгеләнгән контроль саннар белән чикләнеп, әлеге Законның 20 статьясы нигезендә расланган тәртиптә максатчан кабул итүне гамәлгә ашырырга хокуклы” сүзләрен “кабул итүнең билгеләнгән контроль саннары белән чикләнеп, Федераль законның $71^1$ статьясында билгеләнгән тәртиптә максатчан укытуга кабул итүне гамәлгә ашыралар” сүзләренә алмаштырырга;

3) 20 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“20 статья. **Максатчан укыту**

1. Урта һөнәри белем яисә югары белем бирүнең уку-укыту программасы буенча укырга керүче йә тиешле уку-укыту программасы буенча белем алучы граждан федераль дәүләт органы, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органы, юридик зат яисә индивидуаль эшкуар (алга таба – максатчан укытуга заказ бирүче) белән максатчан укыту турында шартнамә төзергә хокуклы. Максатчан укыту турында шартнамәнең төп шартлары Федераль закон нигезендә билгеләнә.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән граждан һәм максатчан укытуга заказ бирүче белән беррәттән максатчан укыту турында шартнамәнең яклары шулай ук белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма һәм (яисә) граждан максатчан укыту турында шартнамә нигезендә эшкә урнашачак оешма да булырга мөмкин.

3. Максатчан укыту турында шартнамә төзегән граждан белем ала торган белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма, күрсәтелгән гражданның практика үтүен оештырганда, максатчан укытуга заказ бирүченең тәкъдимнәрен исәпкә ала, шулай ук максатчан укытуга заказ бирүченең соратуы буенча аңа гражданның уку-укыту программасын үзләштерү нәтиҗәләре хакында мәгълүмат бирә.

4. Максатчан укытуга заказ бирүче максатчан укыту турында шартнамә төзегән гражданны эшкә урнаштыру буенча максатчан укыту турында шартнамәдә каралган йөкләмәләрне үтәмәгән очракта, максатчан укытуга заказ бирүче максатчан укыту турында шартнамә нигезендә белем алуга (укуны тәмамлауга) бәйле рәвештә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмадан чыгару датасына Россия Федерациясенең тиешле субъекты территориясендә эшкә урнашырга тиешле гражданга шушы субъекттагы өч уртача айлык исәпләнгән хезмәт хакы күләмендә компенсация түли.

5. Максатчан укыту турында шартнамә төзегән граждан уку-укыту программасын үзләштерү һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру буенча максатчан укыту турында шартнамәдә каралган йөкләмәләрне үтәмәгән очракта, ул өч ел дәвамында максатчан укытуга заказ бирүченең ярдәм чараларын күрсәтүгә бәйле чыгымнарын капларга тиеш.

6. Дәүләт оешмаларының һәм муниципаль оешмаларның тиешле квалификация белгечләренә ихтыяҗын канәгатьләндерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты мәгариф оешмалары тарафыннан дәүләт аккредитациясе булган урта һөнәри белем һәм югары белем бирүнең уку-укыту программалары буенча гамәлгә ашырыла торган өстенлекле әзерлек юнәлешләре (белгечлекләр) исемлеген билгели һәм “Интернет” челтәрендәге рәсми сайтта урнаштыра.

7. Максатчан укыту турында шартнамәне төзү һәм өзү тәртибе, хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру урынын билгеләү һәм үзгәртү шартлары, якларны максатчан укыту турында шартнамә йөкләмәләрен үтәүдән азат итү тәртибе һәм

нигезләре, компенсация түләү тәртибе, чыгымнар күләмен билгеләү һәм аларны каплау тәртибе дә керә торган максатчан укыту турындагы нигезләмә һәм максатчан укыту турында шартнамәнең типлаштырылган рәвеше Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

8. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органы, дәүләт (муниципаль) учреждениесе, унитар предприятие, дәүләт компаниясе яисә устав капиталында Татарстан Республикасы яисә Татарстан Республикасында муниципаль берәмлек өлеше булган хуҗалык ширкәте белән максатчан укыту турында шартнамә төзегән граждан “Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында” 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә социаль ипотека системасында гражданнарга дәүләт ярдәме чараларыннан файдаланырга хокуклы.

9. Бер ягы дәүләт органы яисә җирле үзидарә органы булган һәм максатчан укыту турында шартнамә төзегән гражданның укуны тәмамлаганнан соң дәүләт хезмәте яисә муниципаль хезмәт узу йөкләмәсе кертелгән максатчан укыту турында шартнамә төзү үзенчәлекләре дәүләт хезмәте төрләре турындагы федераль законнарда яисә муниципаль хезмәт турындагы законнарда урнаштырылган тәртиптә билгеләнә.

10. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетының һәм Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләр җирле бюджетларының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән максатчан укыту турында шартнамә буенча һөнәри белем алган гражданнарның эшкә урнашуын чираттагы уку елы йомгаклары буенча мониторинглауны һәм шушы мониторингны Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының “Интернет” челтәрендәге рәсми сайтларында, 1 сентябрьдән дә соңга калмыйча, урнаштыруны тәэмин итә.”;

4) 25 статьяның 4 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы органы карары буенча эш вакытында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең уку-укыту программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясен үткәрүдә катнашучы һәм әлеге дәүләт йомгаклау аттестациясен үткәрү чорына төп эшеннән азат ителгән мәгариф оешмаларының педагог хезмәткәрләренә хезмәт законнарында һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка актларда билгеләнгән гарантияләр һәм компенсацияләр бирелә. Төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең уку-укыту программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясен үткәрүдә катнашучы педагог хезмәткәрләргә әлеге дәүләт йомгаклау аттестациясен әзерләү һәм үткәрү эше өчен компенсация түләнә. Мондый компенсация күләме һәм аны түләү тәртибе Татарстан Республикасы бюджетыннан төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең уку-укыту программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясен үткәрүгә бүлеп бирелә торган акчалар чикләрендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.”.

**2 статья**

1. Әлеге Закон 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

2. “Мәгариф турында” 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (әлеге Закон редакциясендә) нигезләмәләренең гамәлдә булуы әлеге Закон үз көченә кергәнче төзелгән максатчан кабул итү турында шартнамәләрдән һәм максатчан укыту турында шартнамәләрдән килеп чыккан хокук мөнәсәбәтләренә кагылмый.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 20 декабрь
№ 105-ТРЗ